# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Азнакай районы һәм Азнакай шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Азнакай районы һәм Азнакай шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 113-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Азнакай районы һәм Азнакай шәһәре
буенча Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының суд
участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай районы һәм Азнакай шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

## 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көньяк чиге Азнакай – Бөгелмә автомобиль юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, базар һәм автовокзалны кертеп, Азнакай – Бөгелмә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба Гагарин һәм Ленин урамнары белән кисешкәнгә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамы күчәре буйлап төньякка таба Ленин һәм Нефтьчеләр урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Нефтьчеләр урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Солтангалиев урамы белән кисешкәнгә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Солтангалиев урамы күчәре буйлап көньякка таба Солтангалиев урамындагы 27 нче йортка кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм "Дружба" бакчачылык җәмгыятенә кадәр уза, алга таба, бакчачылык җәмгыяте территориясен кертеп, "Дружба" бакчачылык җәмгыятенең чиге буйлап көнбатышка таба "Юбилейный" стадионына кадәр бара, стадионны урап ала һәм "Дружба" бакчачылык җәмгыятенең төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба Шәйхетдинов урамына кадәр уза, аннары, уң якта урнашкан сәнәгать предприятиеләрен кертеп, Шәйхетдинов урамы буйлап төньякка таба Җәлил урамы белән кисешкәнгә кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Җәлил урамы күчәре буйлап көнчыгышка таба Азнакай – Тымытык автомобиль юлына кадәр уза, аннары, "Строитель" бакчачылык җәмгыяте территориясен кертеп, автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнчыгышка таба шәһәрнең төньяк чигендә, Сәпәй һәм Уразай авыл җирлекләре чикләре тоташкан җирдә урнашкан тоташу ноктасына кадәр бара, алга таба "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиге буйлап көньякка таба шәһәрнең көньяк чиге Азнакай – Бөгелмә автомобиль юлы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Азнакай муниципаль районының Әсәй, Балтач, Вахитов, Югары Стәрле, Карамалы, Сарлы, Туйкә, Уразай, Урманай, Үчәлле һәм Чемодурово авыл җирлекләре.

## 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге "Азнакай шәһәре", Сәпәй һәм Уразай авыл җирлекләре муниципаль берәмлекләре чикләре тоташкан җирдә, Азнакай шәһәренең төньяк-көнчыгыш чигенең Азнакай – Тымытык автомобиль юлы белән кисешкән җирдә урнашкан тоташу ноктасыннан алып, уң якта урнашкан урман посадкасын һәм "Мичуринец" бакчачылык җәмгыятен кертеп, автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнбатышка таба Җәлил урамына кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны ("Татнефтестрой" ААҖ) кертеп, аның күчәре буйлап көнбатышка таба Шәйхетдинов урамы белән кисешкәнгә кадәр бара, алга таба, уң якта (Гафури, Кәрим, Давыдов, Гыйззәт һәм Бакча урамнарында) урнашкан йортларны кертеп, Шәйхетдинов урамы күчәре буйлап көньякка таба Бакча урамындагы 2А йортка кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба борыла һәм, уң якта урнашкан йортларны кертеп, "Дружба" бакчачылык җәмгыятенең төньяк чиге буйлап Котовский урамындагы 27 нче йортка кадәр бара, шуннан соң көньякка таба борыла, автомобильләр туктап тору урыннары территориясен кертеп, автомобильләр туктап тору урыннары белән "Юбилейный" стадионы арасыннан уза, алга таба, Спорт боз сараен, Мәдәният сараен һәм су спорты комплексын кертеп, стадионның чиге буйлап "Дружба" бакчачылык җәмгыятенең көнбатыш чигенә кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан (Нефтьчеләр урамындагы 27 һәм 36 нчы) йортларны кертеп, бакчачылык җәмгыятенең чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба Солтангалиев урамына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба бара, аннары, Солтангалиев урамындагы 25Б, 25А һәм 25 нче йортларны кертеп, Солтангалиев урамы күчәре буйлап төньякка таба Нефтьчеләр урамы белән кисешкәнгә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Нефтьчеләр урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Ленин һәм Нефтьчеләр урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамы күчәре буйлап төньякка таба Җиңү мәйданына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, Мәрҗани урамындагы йортларны кертеп, Мәрҗани һәм Төзүчеләр урамында урнашкан йортлар арасыннан Хәсәншина тыкрыгына кадәр бара, аннары, уң якта (Әхмәдиев урамы буйлап) урнашкан йортларны кертеп, тыкрык буйлап көньякка таба уза, Хәсәншина урамындагы 3 нче йорт яныннан төньяк-көнбатышка таба борыла һәм Әхмәдиев урамы буйлап, әлеге урамда урнашкан йортларны кертеп, чокырга кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, уң якта урнашкан йортларны, предприятиеләрне һәм оешмаларны кертеп, чокыр уйсулыгы буйлап Лениногорск трактына кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Лениногорск трактының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнбатышка таба Әлмәт

тракты белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан Мәнәвез авылын кертеп, Әлмәт трактының күчәр сызыгы буйлап шәһәрнең көнбатыш чигенә кадәр уза, алга таба "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба "Азнакай шәһәре", Сәпәй һәм Уразай авыл җирлекләре муниципаль берәмлекләре чикләре тоташкан җирдә урнашкан тоташу ноктасына кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Азнакай муниципаль районының Әлкәй, Илбәк, Кәкре Елга, Мәсгут, Сәпәй, Сукаеш, Татар Шуганы, Тымытык, Урсай, Чалпы, Чубар Абдул авыл җирлекләре һәм Әгерҗе авыл җирлегендәге Мәнәвез авылы территориясе.

**3 нче суд участогы**

3 нче суд участогы чигенә "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көнбатыш чигенең Әлмәт тракты белән кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, Яңа Юл поселогын кертеп, трактның күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнчыгышка таба Лениногорск тракты белән кисешкәнгә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан 9 нчы мәктәпне, оешмаларны һәм предприятиеләрне кертеп, Лениногорск трактының күчәр сызыгы буйлап 89 нчы профессиональ лицейның җитештерү базасының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, "Автомобилист" гараж җәмгыяте территориясен кертеп, чокыр уйсулыгы буйлап Әхмәдиев урамына кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба борыла, "Аккош" балалар бакчасын кертеп, Әхмәдиев урамы буйлап Хәсәншина урамына кадәр бара, аннары төньякка таба борыла, Хәсәншина тыкрыгы буйлап, тыкрыкта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр урамына кадәр уза, алга таба, Төзүчеләр урамында урнашкан йортларны кертеп, Мәрҗани һәм Төзүчеләр урамнарында урнашкан йортлар арасыннан Җиңү мәйданына кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамы күчәре буйлап көньякка таба Ленин һәм Нефтьчеләр урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Гагарин урамы һәм Азнакай – Бөгелмә автомобиль юлы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан оешмаларны кертеп, автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнбатышка таба шәһәрнең көньяк чигенә кадәр уза, аннары "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнбатышка таба шәһәрнең көнбатыш чиге Әлмәт тракты белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

3 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы, Мәнәвез авылы территориясеннән башка, Әгерҗе авыл җирлеге, Бирючевка, Мәлбагыш һәм Микулино авыл җирлекләре.